**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
РУКОВОДИТЕЛЬ
КАЗКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО
КОМИТЕТА
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423761, село Казкеево,
ул. Первомайская, дом 2а,
Тел. 3-44-46
Email: kaz-akt@yandex.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӘЗКӘЙ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ ЖИТӘКЧЕСЕ**

423761, Кәзкәй авылы,
Беренче май ур., 2а нчы йорт.
Тел.3-44-46
Email: kaz-akt@yandex.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«03» сентября 2026 года № 14

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы
«Кәзкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча
гомуми тыңлаулар үткәрү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 24,28 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Актаныш муниципаль районының Кәзкәй авыл җирлеге Уставы белән Актаныш муниципаль районының Кәзкәй авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Кәзкәй авыл җирлеге " муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча 2026 елның 21 сентябрендә гомуми тыңлаулар билгеләргә.

2. Гомуми тыңлауларны үткәрү урыны итеп түбәндәге урыннарны билгеләргә: Кәзкәй авылы, Беренче Май ур., 1а йорт, үткәрү вакыты 14:00 сәгать; Тыңламас авылы, Октябрь ур., 72Б йорт, үткәрү вакыты 18:00 сәгать.

3. Гомуми тыңлауларда карала торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Кәзкәй авылы, Беренче Май ур., 2а.

4. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтындагы "авыл җирлекләре" бүлегендә: http:/aktanysh.tatarstan.ru.

5. Әлеге карар халыкка игълан ителгән мизгелдән үз көченә керә.

Кәзкәй авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р.Шайхуллин